РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» февраль 2021 ел г. Альметьевск № 199

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районының авыл
җирендә (шәһәр тибындагы
поселокларда) эшләүче һәм
яшәүче аерым категориядәге
гражданнарга торак һәм коммуналь
хезмәтләр өчен түләү буенча
социаль ярдәм чаралары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының авыл җирендә (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә торак, җылылык, ут өчен түләү чыгымнарының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә 100 проценты күләмендә ярдәм чарасы һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәләр булган очракта коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары буенча ярдәм итү чарасын бирергә.

Социаль ярдәмнең күрсәтелгән чарасы шулай ук пенсиягә чыккан гражданнарга да, шулай ук «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» 2001 елның 15 декабрендәге 166-ФЗ номерлы федераль законнарда каралганча, 2018 елның 31 декабренә торышы буенча 60 һәм 55 яшькә җитмәгән (ир-атлар һәм хатын-кызлар), авыл җирлегендә (шәһәр тибындагы поселокларда) яшәүче һәм

Зак. № 305-2000

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының авыл җирлегендә (шәһәр тибындагы поселокларда) урнашкан муниципаль мәдәният учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән күрсәтелгән хезмәткәрләргә бирелә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Шәйдуллина З.Р.) ел саен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының авыл җирендә (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү өчен, чираттагы елга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мәдәният идарәсе бюджетында акча бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мәдәният идарәсенә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының авыл җирендә (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - ЕГИССО) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының авыл җирендә (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында мәгълүматне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә ЕГИССО куллану юлы белән алынырга мөмкин.

4. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Хезмәткәрләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2007 елның 18 гыйнварындагы 41 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ